«12» ноябрь 2022 ел № 4

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә гражданнарга үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: - Яр буе Морквашы авылының Кәрим Тинчурин урамындагы җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау, дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 12 ноябрендә үткән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 7 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 2 кеше. Кворум юк.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә халык җыены үткәрелмәгән дип танырга.

2. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х.Гаязов